ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.07.2026 Олы Кайбыч ав. № 365

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль белем бирү оешмаларын булдыру, үзгәртеп оештыру һәм бетерү тәртибен раслау турында» 2026 елның 18 маендагы 232 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль белем бирү оешмаларын булдыру, үзгәртеп оештыру һәм бетерү тәртибен раслау турында» 2026 елның 18 маендагы 232 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- кушымтаның 3.12 пунктын түбәндәге эчтәлекле 8 пункча белән тулыландырырга:

«8) балигъ булган укучыларны аларның ризалыгы белән һәм балигъ булмаган укучыларны аларның ата-аналары (законлы вәкилләре) ризалыгы белән тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлешле белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешмаларга күчерүгә академик хокук бирергә.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров